ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Җир асты байлыклары турында” Татарстан Республикасы Законының 7 һәм 19 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2014 елның 20 мартында
кабул ителде

## 1 статья

“Җир асты байлыклары турында” 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1, № 7 (I өлеш), № 12 (II өлеш); Ватаным Татарстан, 2014, 22 гыйнвар) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 7 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле яңа унбишенче абзац өстәргә:

“җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлекләренә карата тау эшләре кишәрлегенең төгәлләштерелгән чикләрен таныклый торган һәм лицензиягә аның аерылгысыз состав өлеше буларак кертелә торган документларны (тау эшләре өчен бүлеп бирелгән кишәрлек турында акт һәм график кушымталар) рәсмиләштерү (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән очракларда);”;

б) унбишенче абзацны уналтынчы абзац дип санарга;

2) 19 статьяның беренче өлешендә:

а) өченче абзацта “планнары һәм схемалары” сүзләрен “планнары яисә схемалары” сүзләренә алмаштырырга;

б) түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

“файдалануга бирелгән җир асты байлыклары кишәрлеге чикләрендә урнашкан тау эшләнмәләренең, бораулау скважиналарының һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга бәйле башка корылмаларның иминлеген.”.

**2 статья**

1. Әлеге Закон, әлеге статья белән үз көчләренә керүнең башка вакытлары билгеләнгән нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 1 пункты, 2 пунктның “а” пунктчасы 2014 елның 1 июленнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2014 елның 11 апреле
№ 20-ТРЗ